РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

КАРАР

10 ноябрь 2025 ел №1

**«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 24 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
2. 2025 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
3. 2025 елның 25 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: :«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация

буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл жирлегенең Ядегәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су жыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- тротуарларны төзү, ремонтлау;
- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;
- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны жыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

7.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин